**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Алькеевского сельского
поселения
Азнакаевского муниципального
района

Пер.Советский,44а,
423309 Тел. ( 885592) 37-4-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСI**

Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл жирлеге
комитеты

Пер.Советский, 44а
Әлкэй авылы, 423309
Тел. (885592) 37-4-23

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.07.2020 ел №18

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районының «Әлкәй авыл жирлеге» муниципаль
берәмлегенең жирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләренә үзгәрешләр керту проекты буенча
ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексыныц 31 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЭ номерлы «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законный 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әлкәй авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл жирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм уткәру тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып карар итәм:
1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл ж;ирлеге Советының 2014 елныц 22 гыйнварындагы 67 нче номерлы карары белән расланган (15.11.2016 №42, 21.11.2016 №40-24, 04.09.2017 №62, 03.07.2018 №102, 18.03.2019 №128, 18.02.2020 №163 карарлар редакциясендә), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Әлкәй авыл жирлеге" муниципаль берәмлегенең жирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.
1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында
- ТР, Азнакай муниципаль районы, Әлкәй авыл жирлеге, Әлкәй авылы, Мәктәп урамы, 35А йорт адресы буенча урнашкан мәйданы 40 кв.м, 16:02:020101:323 кадастр номерлы жир кишәрлеге өчен территориаль Күпфункцияле иҗтимагый- эшлекле зонадан ОД1 дән индивидуаль торак төзелеше зонасына Ж1 күчерү.
2. Билгелэргә:
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл жирлегендә жирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләу буенча комиссияне ачык тыңлауларны оештыручы итеп;
- уткәру вакыты-2020 елның 3 июленнән 2020 елның 04 августына, 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны- Әлкәй авылы, Совет урамы 34;
- 2020 елның 04 августына кадәр фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Әлкәй авылы, Пер.Совет ур.44А йорт, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл жирлеге башкарма комитеты.
3. Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл жирлегендә жирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләу буенча комиссиягә:
- Азнакай муниципаль районы «Әлкәй авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең жир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә узгәрешләр кертү проекты буенча гамәлдәге законнар һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар

әзерләргә һәм үткәрергә; - ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

- Азнакай муниципаль районының «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http ://aznakayevo.tatarstan. ru.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo. tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Башлык С.З.Зиннурова